ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур.15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 168

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

18 октябрь 2021 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның 25 декабрендәге 479 номерлы, 2020 елның 3 августындагы 151 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 202 номерлы, 2020 елның 17 декабрендәге 221 номерлы, 2021 елның 4 июнендәге 90 номерлы, 2021 елның 29 июнендәге 111 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н.Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясенең 2021 елның
«18» октябрендәге 168 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4 пунктта:

бишенче абзацта «(http://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләреннән соң «(алга таба – Республика порталы)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «(http://www.gosuslugi.ru/)» сүзләреннән соң «(алга таба – Бердәм портал)» сүзләрен өстәргә;

1.4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. ТР Дәүләт торак инспекциясенең урнашкан урыны, белешмә телефоны, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.4.2 пунктчаның беренче абзацында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында» сүзләрен «Бердәм порталда, Республика порталында» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның җиденче абзацында «1 нче, 3 нче, 4 нче кушымталарда» сүзләрен «1 нче, 3 нче, 7 нче, 10 нчы кушымталарда» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү

## 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – Дәүләт торак инспекциясе).

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

а) лицензия бирү (бирүдән баш тарту) (әлеге Регламентка 12 нче, 13 нче кушымталар);

б) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту) (әлеге Регламентка 14 нче, 15 нче кушымталар);

в) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында белешмәләр, кабул ителгән карар турында ТР Дәүләт торак инспекциясе акты күчермәсен яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә бирү (әлеге Регламентка 8 нче кушымта);

г) лицензиянең гамәлдә булуын туктату һәм лицензияне юкка чыгару турында карар (әлеге Регламентка 16 нчы кушымта);

д) лицензиянең гамәлдә булу чорын арттыру (арттырудан баш тарту) турында карар (әлеге Регламентка 17 нче, 18 нче кушымталар);

е) лицензия алырга теләүче зат, лицензиат турындагы мәгълүматларны күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга лицензияләр реестрына (алга таба – лицензияләр реестры) кертү.

ж) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (кертү мөмкинлегенең булмавы) (әлеге Регламентка 21 нче, 22 нче кушымталар).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә ТР ДТИ җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Бердәм порталда, Республика порталындагы мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан җибәрелгән, күпфункцияле үзәкнең мөһере һәм күпфункцияле үзәк хезмәткәренең имзасы белән таныкланган, кәгазьдә бастырылган электрон документ нөсхәсе рәвешендә күпфункцияле үзәктән дә алына ала.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яки кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак, мөрәҗәгать итүче, ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен шәхсән ТР Дәүләт торак инспекциясендә кәгазьдә алырга хокуклы.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия

Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы:

а) ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензия бирү турында лицензия алырга теләүче затның гаризасын һәм аңа теркәлгән документларны карау – лицензия бирү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган, аңа теркәлә торган документларны (мәгълүматларны) тулы күләмендә кабул иткән көннән башлап 30 эш көне;

б) күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе (алга таба – лицензия комиссиясе) тарафыннан лицензия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында ТР Дәүләт торак инспекциясеннән нигезле тәкъдим буенча карар кабул итү – лицензия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында ТР Дәүләт торак инспекциясеннән нигезле тәкъдим лицензия комиссиясенә алынган көннән башлап 4 эш көне;

в) лицензия бирү турында (лицензия бирүдән баш тарту турында) ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы лицензия комиссиясе карары кабул ителгәннән соң 2 эш көне эчендә чыгарыла;

г) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) карар кабул итү (үзгәртеп кору формасында юридик затны үзгәрткән, аның исемен, урнашкан урыны адресын үзгәрткән очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгән очракта) – ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, аңа теркәлә торган документлар (белешмәләр) тулы күләмендә килгән көннән башлап 10 (ун) эш көне;

д) лицензия бирү турында (лицензия бирүдән баш тарту), лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту) турында белдерү җибәрү – лицензияне имзалау һәм лицензияләр реестрында теркәү көненнән соң 3 эш көне;

е) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә билгеле бер лицензия турында мәгълүматлар яисә соралган белешмәләрнең булмавы турында белешмә, кабул ителгән карар турында ТР Дәүләт торак инспекциясе акты күчермәсен бирү – тиешле гариза алынган көннән башлап 3 эш көне;

ж) лицензиянең гамәлдә булуын туктату һәм лицензияне гамәлдән чыгару – күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза; юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан тиешле реестрга юрдик затның эшчәнлеген туктатуы турында яки физик затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турында язу кертелү датасы турында мәгълүмат; лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карары (лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карарыннан өземтә) ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап – 10 эш көне эчендә;

з) лицензиянең гамәлдә булуын озынайту турында (лицензиянең гамәлдә булуын озынайтудан баш тарту турында) карар кабул итү - ТР Дәүләт торак инспекциясенә тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза алынган датадан башлап 30 календарь көн.

и) техник хатаны төзәтү – хатаны төзәтү турында гариза алынган датадан башлап 5 эш көне эчендә;

к) лицензиат – юридик затның урнашкан урыны, лицензиат – шәхси эшкуарның яшәгән урыны, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны үгәртелгән очракта, географик объектны, урамны, мәйданны яки номерын, шул исәптән почта индексын да, үзгәртеп башка төрле территорияне үзгәртеп атауга бәйле булса, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү – лицензиаттан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турындагы гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган көннән башлап 5 эш көне эчендә;

л) ТР Дәүләт торак инспекциясендә географик объектны, урамны, мәйданны яки башка төрле территорияне үзгәртеп атау, нумерацияне, шул исәптән почта индексын да үзгәртү турында мәгълүмат булган очракта, лицензияләр реестрына ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан үзгәрешләр кертелүе турында белдерү – лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгән көннән башлап 5 эш көне эчендә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

### 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Лицензия алу өчен түбәндәге документлар (мәгълүматлар) тапшырыла:

а) лицензия бирү турында гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

б) лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының (юридик затның бер кулдагы башкарма органының, юридик зат җитәкчесенең яки аның филиалы җитәкчесенең яки шәхси эшкуарның) квалификация аттестаты күчермәсе;

в) лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затын билгеләп кую турында боерык күчермәсе;

г) теркәлә торган документлар исемлеге.

2.5.2. Юридик затны үзгәртеп формалаштыру рәвешентә үзгәрткәндә, юридик затның атамасы, аның урнашу урыны, шулай ук шәхси эшкуарның яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, шәхесен таныклаучы документ реквизитлары үзгәргән очракта, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен түбәндәгеләр тапшырыла:

а) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);

б) кәгазь чыганакта булган очракта, лицензиянең оригиналы;

в) документлар исемлеге.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә нигез булган очрак барлыкка килгән көннән башлап 15 эш көненнән соңга калмыйча тапшырыла.

2.5.3. Конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан өземтә яки кабул ителгән карар турында ТР Дәүләт торак инспекциясе акты күчермәсе яисә лицензияләр турындагы мәгълүматлар лицензияләр реестрында булмаган очракта яки конкрет лицензиатны билгеләү мөмкинлеге булмаганда бирелә торган, сорала торган мәгълүматларның булмавы турында белешмә рәвешендә мәгълүматлар алу өчен физик заттан яки юридик заттан мондый мәгълүматларны тапшыру турында гариза бирелә (әлеге Регламентка 7 нче кушымта).

2.5.4. «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 99-ФЗ номерлы федераль закон) 20 статьясының 13 өлешендәге 1 пунктында каралган очракта лицензиянең гамәлдә булуын туктату өчен күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза тапшырыла, анда күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге фактта туктатылган дата күрсәтелә (әлеге Регламентка 9 нчы кушымта).

2.5.5. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын арттыру өчен түбәндәгеләр тапшырыла:

а) лицензиянең гамәлдә булу вакытын арттыру турында гариза (әлеге Регламентка 10 нчы кушымта);

б) лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының (юридик затның бер кулдагы башкарма органының, юридик зат җитәкчесенең яки аның филиалы җитәкчесенең яки шәхси эшкуарның) квалификация аттестаты күчермәсе;

в) лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затын билгеләп кую турында боерык күчермәсе;

г) теркәлә торган документлар исемлеге.

2.5.6. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтү өчен мөрәҗәгать итүче техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) белән мөрәҗәгать итә.

2.5.7. Лицензиат – юридик затның урнашкан урыны, лицензиат – шәхси эшкуарның яшәгән урыны, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны үгәртелгән очракта, географик объектны, урамны, мәйданны яки номерын, шул исәптән почта индексын да, үзгәртеп башка төрле территорияне үзгәртеп атауга бәйле булса, лицензияләр реестрына үзгәреш кертү өчен лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза тапшырыла (әлеге Регламентка 11 нче кушымта).

2.5.8. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

шәхсән;

почта юлламасы белән;

КФҮ аша;

Бердәм портал аша электрон рәвештә;

Республика порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза кәгазен мөрәҗәгать итүче ТР Дәүләт торак инспекциясенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.9. Гаризаны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Бердәм портал, Республика порталы аша электрон рәвештә тапшырганда (җибәргәндә), гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзалана.

## 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәгеләр карамагында булган документлар (белешмәләр) кирәк:

а) Федераль казначылык – дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүматлар;

б) Федераль салым хезмәте – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр;

в) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы – лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затының икътисад, урта авырлыктагы җинаятьләр, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгән яки үтәп бетерелмәгән хөкеменең булуы (булмавы) турында белешмәләр;

г) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы – лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи заты турында лицензиясе юкка чыгарылган лицензиатның бер үзе генә тарафыннан башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашырган затлар, шулай ук лицензиат уставында яки башка документлары нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү бурычы йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган затлар, лицензияләре юкка чыгарылган һәм (яки) үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган шәхси эшкуарлар реестрында мәгълүмат булуы (булмавы) турында, шулай ук лицензия алырга теләүче затка элегрәк бирелгән лицензияне юкка чыгару турында лицензияләрнең җыелма федераль реестрында мәгълүмат булмавы турында белешмәләр.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да кертеп, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтә торган дәүләт органнары карамагында булган документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

1) мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

2) документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы.

3) тапшырылган документлар яисә белешмәләрнең хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән вакытта үз көчләрен югалтуы (шәхесне раслаучы документ белешмәләре; мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, хезмәт күрсәтү өчен әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта);

4) хезмәт күрсәтү турындагы гаризаның һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылуы;

5) гариза формасында, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив формасында, кырларның тулысынча тутырылмавы;

6) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган җыелмасы тапшырылганда;

7) хезмәт күрсәтү турындагы гаризаның хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына тапшырылуы;

8) 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве.

2.7.2. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында, ТР ДТИ рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) лицензия бирүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

а) лицензия бирү турындагы гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны тикшергәндә лицензия алырга теләүче лицензия таләпләренә туры килмәгән очракта;

б) лицензия алырга теләүче зат тарафыннан лицензия бирү турында тапшырылган гаризада һәм (яки) аңа теркәлә торган документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булган очракта;

2) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

а) лицензия бирү турындагы гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны тикшергәндә лицензия алырга теләүче лицензия таләпләренә туры килмәгән очракта;

б) лицензия алырга теләүче зат тарафыннан лицензия бирү турында тапшырылган гаризада һәм (яки) аңа теркәлә торган документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булган очракта;

3) әгәр дәүләт серен яки хезмәт серен саклау мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый белешмәләрдән ирекле файдалану чикләнгән булса, лицензияләрнең бердәм реестрыннан мәгълүмат бирүдән баш тартыла.

2.8.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында, ТР ДТИ рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

2.9.1. Дәүләт пошлинасы:

күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү – 30000 сум;

күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – 5000 сум;

Лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермәдәге өземтә өчен түләү – 3000 сум.

2.9.2. Түләү реквизитлары:

Бердәм казна счеты: 40102810445370000079

Керемнәрне исәпкә алу һәм бүлү операциясен гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казна счеты: 03100643000000011100

Банк: Татарстан Республикасы Милли банкы бүлекчәсе – Россия банкы Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре

БИК: 019205400

Түләү алучының ИНН (61) - 1653015798

Алучының КПП (103) – 165501001

«Алучы» кыры (16) – ТР буенча ФКИ (ТР Финанс министрлыгы (ТР ДТИ)

Шәхси счет ЛБ 007140000-ГосЖилИн) 104 кырында бюджет классификациясенең киләсе коды күрсәтелә:

71410807400011000110 Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтле органнарының күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләүгә бәйле гамәлләре өчен дәүләт пошлинасы

Муниципаль берәмлекләр территорияләренең россиякүләм классификаторы нигезендә ОКТМО.

Исәп-хисап документының түләүнең билгеләнеше кырында (24) түләүнең билгеләнешен идентификацияләү өчен кирәкле булган өстәмә башка мәгълүматны күрсәтергә рөхсәт ителә «Түләүченең статусы» кырында (101): 08 тутыру өчен мәҗбүри.

2.9.3. Лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендәге лицензияләр реестрыннан өземтә түләү алмыйча бирелә.

2.9.4. Түләү кире кайтарылырга тиеш:

а) тулы күләмдә, әгәр ТР Дәүләт торак инспекциясенә кәгазьдәге өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында гариза тапшырылмаган булса;

б) билгеләнгән түләү күләменнән артып киткән күләмдә түләү кертелгән очракта, 3000 сумны арттырган өлешендәге күләмдә;

в) түләү тулы күләмдә кертелмәгән очракта, кертелгән түләү күләмендә.

2.9.5. Түләүне кире кайтару турында гариза түләү кертелгәннән соң өч ел эчендә тапшырылырга мөмкин.

2.9.6. Мөрәҗәгать итүче өземтә алудан баш тарткан очракта, аны бирү өчен кертелгән түләү кире кайтарылмый. Шулай ук түләү лицензия реестрында соратып алына торган мәгълүматлар булмаган очракта да кире кайтарылмый.

2.9.7. Түләүне кире кайтару түләү мөрәҗәгать итүченең анда күрсәтелгән банк реквизитларына, түләүне кире кайтару турында гариза биргән көннән бер ай эчендә күчерелә.

2.9.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә алдан тутырылган реквизитлар буенча башкарыла ала.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләгәндә мөрәҗәгать итүчегә түләү документының тутырылган яки өлешчә тутырылган, шулай ук тутырылган түләү документының күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә.

Түләү документында исәпләмәнең уникаль идентификаторы һәм түләүченең идентификаторы күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы факты турында мөрәҗәгать итүчегә Бердәм портал, Республика порталы аша хәбәр ителә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Лицензия алырга теләүче зат (лицензиат) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм (яки) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көннән соң бер көн эчендә теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан күпфункцияле үзәк аша бирелгән гариза ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гариза күпфункцияле үзәктән алынган көнне теркәлә.

2.13.4. Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза тапшырылган көнне мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан язу бирелә.

2.13.5. Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.13.6. ТР Дәүләт торак инспекциясе, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мондый документларны яңадан кәгазьдә тапшыру зарурлыгыннан башка гына, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә һәм гаризаны терки.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итә алу үзлеге бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска ярдәмендә дә;

5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртә торган этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгында билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, сукырларны йөртә торган этне кертү;

9) хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.14.3. Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кулланыла торган, Регламентның 2.14.2 пунктының 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң эксплуатациягә кертелгән яки модернизация, реконструкция узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру (алга таба – комплекслы мөрәҗәгать) юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) яки андый мөмкинлекнең булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

б) белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итеlә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында ТР Дәүләт торак инспекциясенең мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Бердәм порталда тулы мәгълүмат булуы;

г) гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

д) инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:

а) документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләр аларны тапшырганда чиратлар;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозулар;

в) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләре гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;

г) дәүләт хезмәтен күрсәткән граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазифаи зат белән мөрәҗәгать итүче арасында бер мәртәбә хезмәттәшлек итү күздә тотыла. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, ТР ДТИ рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында, КФҮ сайтында алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә тиешле гамәл ахырына җиткереп үтәлгәннән соң бер эш көненнән дә артмаган вакытта электрон почта адресына яисә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, Бердәм портал, Республика порталы, рәсми сайт чараларыннан файдаланып җибәрелә.

2.15.5. Мөрәҗәгать итүчеләргә Бердәм портал, Республика порталы, терминал җайланмалары ярдәмендә дәүләт хезмәтләренең үтемлелеген һәм сыйфатын бәяләү мөмкинлеге тәэмин ителә.

2.15.6. Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

## 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризалар электрон формада тапшырыла.

Гаризаны тапшыру өчен ТР ДТИ тарафыннан кабул итүгә язылу Республика порталыннан файдаланып гамәлгә ашырылмый.

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

д) Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә ТР ДТИ, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган хисапны форматы-мантыйгы ягыннан тикшерү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы барлык юлларны тутырганнан соң автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне КФҮ кабул итү өчен язу (алга таба – кабул итүгә язу) Республика порталы, КФҮ элемтәләр үзәге ярдәмендә һәм КФҮ урнаштырылган электрон чират белән идарә итү системасы терминалы аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу вакыты әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

2.16.4. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.»;

3 бүлектә:

бүлек аталышын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

3.3.1 пунктның өченче абзацында «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «Бердәм портал, Республика порталы аша» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. ТР Дәүләт торак инспекциясенә гариза тапшырылганда җаваплы башкаручы:

а) гаризаны һәм башка документларны исемлек буенча кабул итә;

б) документларның комплектлылыгын тикшерә;

в) гариза формасы буенча гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүмат (белешмәләр, күрсәткечләр) булуына карата гаризаны тутыруның тулылыгын һәм бирелгән гаризада күрсәтелгән мәгълүматның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) һәм тапшырылган документлар комплектында булган мәгълүматның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) туры килүен тикшерә;

Җаваплы башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында теркәү өчен гаризаны ТР ДТИ гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү һәм эшчәнлек башкару бүлегенә тапшыра. Әлеге гаризаларны һәм документларны кабул итү датасында тамгалап, исемлек күчермәсен лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка

тапшыра яисә кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән яки гаризаларда күрсәтелгән электрон адреска җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар барлык кирәкле документлар белән гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кушымталары булган документлары белән теркәүгә алынган гариза.»;

3.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. ТР Дәүләт торак инспекциясенә гариза алынганда һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктының 1, 2, 3, 5, 7, 8 пунктчаларында каралган нигезләр булуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы, сәбәбен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү әзерли, мондый белдерүне почта аша кулга тапшыру турында тамгасы белән җибәреп яисә, лицензия алырга теләүче зат, лицензиат ихтыярына карап, лицензия бирә торган органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка мондый белдерүнең җиткерелүен һәм лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан аның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән бирә (Регламентка 23 нче кушымта).

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы 4, 6 пунктчаларында каралган нигезләр ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы аларны кабул итүдән соң 2 эш көне эчендә лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка утыз көн эчендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү кирәклеге һәм (яки) җитешмәгән документларны тапшыру турында лицензия алырга теләүче затка белдерү (Регламентка 24 нче кушымта) бирә яки мондый белдерүне, лицензия алырга теләүче зат, лицензиат ихтыярына карап, лицензия бирә торган органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, мондый белдерүнең җиткерелүен һәм лицензия алырга теләүче зат тарафыннан алынуын раслый торган ысул белән, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Лицензия алырга теләүче зат, лицензиат тарафыннан, белдерү алынган вакыттан башлап, лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензия бирү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензия алырга теләүче затка кире кайтарылырга тиеш.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, җаваплы башкаручы лицензия бирү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, аңа теркәлә торган документлар тулы күләмендә алынган көннән башлап 2 эш көне эчендә планнан тыш документлар тикшерү уздыру турында проект әзерли.

Юридик бүлек җитәкчесе планнан тыш документлар тикшерү уздыру турындагы боерык (күрсәтмә) проектын килештерә, ул ТР Дәүләт торак инспекциясе

җитәкчесе урынбасары – лицензия бирү мәсьәләләрен алып баручы хокук идарәсе җитәкчесенә (алга таба – җитәкче урынбасары) җибәрелә.

Җитәкче урынбасары планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкны (күрсәтмәне) имзалый.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) җитмәгән документларны тапшыру кирәклеге турында белдерү, гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кайтарып бирү турында белдерү (Регламентка 25 нче кушымта), планнан тыш документлар тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә).

Дәүләт хезмәте күрсәтү (лицензия бирү яисә аны бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү вакыты лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар тулы күләмендә ТР Дәүләт торак инспекциясенә кергән көннән исәпләнә башлый.»;

3.5.1 пунктның икенче абзацында «20 эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.1 пунктның унынчы абзацында «20 эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы лицензияләү комиссиясеннән карар алынган көннән башлап 2 эш көне эчендә чыгарыла. Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе тарафыннан имзалана. Лицензия бирү турындагы боерык реквизитлары лицензияләр реестрына кертелә.

Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгында түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) лицензияләүче органның атамасы – ТР ДТИ;

б) юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы, шул исәптән фирма исеме, оешу-хокук формасы, аның урнашкан урын адресы, лицензияләнә торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, юридик зат оештыру турында язуның дәүләт теркәвенә алу номеры;

в) шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), шәхесен таныклаучы документның исеме һәм реквизитлары, аның яшәү урыны адресы, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу турындагы язуның дәүләт теркәү номеры;

г) салым түләүченең идентификация номеры;

д) лицензияләнә торган эшчәнлек төре - күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеге;

е) лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы номеры һәм датасы.

Татарстан Республикасы лицензия комиссиясенең лицензия бирү турында карары кабул ителгән очракта, лицензия бирү турындагы язу лицензияләр реестрына боерык теркәлгән көнне кертелә.

Лицензияне бирү көне булып лицензияләр реестрына лицензия бирү турындагы язуларны кертү көне тора.

Лицензияләр реестрлары электрон рәвештә формалаштырыла һәм аларга язу кертү рәвешендә алып барыла.

Лицензияләр реестрында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 декабрендәге 2343 номерлы карары белән расланган Лицензияләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләренең 6 пунктында каралган белешмәләр күрсәтелә.

Лицензияләр реестрына кертелгән юридик затка яки шәхси эшкуарга лицензияләр бирү турындагы язуга лицензиянең теркәү номеры булып торган номер бирелә. Лицензиянең теркәү номеры уникаль булып тора. Лицензияләр реестрында бер лицензиатка бирелгән лицензияләрнең теркәлү номеры башка лицензиатка бирелгән лицензияләрнең теркәлү номерын кабатларга тиеш түгел.

Мәгълүмат системасы эшендә техник проблемалар килеп чыгуы аркасында күрсәтелгән срокларда белешмәләрне лицензияләр реестрына кертү мөмкинлеге булмаган очракта, тиешле белешмәләр лицензияләр реестрына лицензияләр реестры алып барыла торган мәгълүмат системасының эшчәнлек сәләте торгызылганнан соң, ләкин лицензияләр реестрына белешмәләр кертү өчен тиешле нигез барлыкка килгән көннән башлап 3 эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.

Лицензиянең теркәү номеры структурасы ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта ТР ДТИ тарафыннан 2020 елның 1 гыйнварына кадәр бирелгән лицензияләрне теркәү номерлары һәм даталары лицензияләрнең теркәү номерлары һәм лицензияләрне бирү даталары буларак лицензияләр реестрына кертелергә мөмкин.

Лицензияләр реестрына белешмәләр ТР Дәүләт торак инспекциясенең лицензияләр реестрына белешмәләр кертүгә вкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кертелә. Лицензияләр реестрына лицензия бирү турындагы язу кертелгән көннән соң өч эш көне эчендә ТР Дәүләт торак инспекциясе лицензиатка, аның ихтыярына карап, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында яисә, тапшыру турында белдереп, кәгазь документ рәвешендә заказлы почта юлламасы итеп, лицензия бирелүе турында белдерү җибәрә, шулай ук бу хакта лицензиатка элемтә чаралары аша һәм тиешле мәгълүматны ТР Дәүләт торак инспекциясенең https://gji.tatarstan.ru рәсми сайтында тиешле мәгълүматны урнаштыру юлы белән дә хәбәр итә.

Лицензия бирү турындагы гаризада лицензияне алырга теләгән зат электрон документ формасында лицензияләр реестрыннан өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, ТР Дәүләт торак инспекциясе, лицензия бирү турындагы белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, лицензияләр реестрыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ формасындагы өземтәне дә лицензиатка бирә (җибәрә).

Лицензия алу турындагы гаризада лицензияне алырга теләгән зат лицензияләр реестрыннан кәгазьдә өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, ТР Дәүләт торак инспекциясе, лицензия бирү турындагы белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, кулга тапшыру турында белдереп, лицензиатка заказлы почта юлламасы итеп лицензияләр реестрыннан өземтә дә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар лицензия комиссиясе карары кабул

ителгәннән соң 2 эш көненнән артмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы, лицензия бирү турында лицензияләр реестрына язу кертү.»;

3.6 пунктның икенче абзацында «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «Бердәм портал, Республика порталы аша» сүзләренә, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында» сүзләрен «Республика порталында» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.3 пунктның өченче абзацында «һәм лицензияләр реестрында теркәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.8.1 пунктның уникенче абзацында «лицензияләр реестрында теркәү» сүзләрен «лицензияләр реестрына белешмәләр кертү» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.12-3.18 пунктларын өстәргә:

«3.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелеге түбәндәге процедураларны эз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) документлар белән гаризаны ТР Дәүләт торак инспекциясенә җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

3.13. Мөрәҗәгать итүчегә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Мөрәҗәгать итүче күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең http ://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

3.14. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша яки электрон формада күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү

буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына документлар тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.15. Документлар пакетын формалаштыру

Күпфункцияле үзәк белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламенты нигезендә:

документлар пакетын формалаштыра һәм аны күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә ТР Дәүләт торак инспекциясенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ТР Дәүләт торак инспекциясенә җибәрелгән документлар.

3.16. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен КФҮ аша бирү турында күрсәтелгән очракта, ТР Дәүләт торак инспекциясе документларны, алга таба мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) тапшыру өчен, КФҮ структур бүлекчәсенә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: КФҮ аша дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.17. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән (яки ышанычлы зат аша) ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан бирелгән лицензияләр реестрындагы өземтәдә техник хатаны төзәтү турында гариза тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.18. Техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны ТР Дәүләт торак инспекциясенә җибәрү.

Күпфункцияле үзәк белгече ТР Дәүләт торак инспекциясе белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны ТР Дәүләт торак инспекциясенә җибәрә.»;

5 бүлектә:

5.2 пунктның өченче һәм алтынчы абзацларында «күпфункцияле үзәк» сүзләрен «КФҮ» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтыннан (https://gji.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр почта буенча, «Интернет» челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан яки 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның сайтларыннан файдаланып, тиешенчә, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләр) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.»;

регламентның 6 нчы бүлеген гамәлдән чыккан дип танырга;

регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы<br>Дәүләт торак инспекциясе<br>тарафыннан күпфатирлы<br>йортлар белән идарә итү буенча<br>эшкуарлык эшчәнлеген<br>лицензияләү буенча дәүләт<br>хезмәте күрсәтүнең<br>административ регламентына<br>1 нче кушымта

Татарстан Республикасы<br>Дәүләт торак инспекциясенә

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген<br>гамәлгә ашыруга лицензия бирү турында

ГАРИЗА

(лицензия бирү өчен беренчел мөрәҗәгать иткәндә)

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү турында сорыйм ________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(лицензия алырга теләүче затның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган атамасы (шул исәптән фирма исеме) күрсәтелә)

Лицензия алырга теләүче затның оешу-хокук формасы __________________
_____________________________________________________________.

Лицензия алырга теләүче затның урнашкан урыны _____________________
_____________________________________________________________.
(лицензия алырга теләүче затның урнашкан урын адресы күрсәтелә)

Юридик затның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) __________________
_____________________________________________________________

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик зат турында белешмәләр кертелү фактын раслаучы документ белешмәләре __________________________
_____________________________________________________________.
_____________________________________________________________.
(дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган органның урнашкан урын адресын күрсәтеп, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язу кертелүе турында таныклык реквизитлары (юридик затны 2016 елның 31 декабреннән соң теркәгән очракта – язу кәгазенең реквизитлары (язу кертү датасы, дәүләт теркәү номеры) (уставка үзгәрешләр кертелү очрагында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язу кертелүе турында барлык тиешле таныклыкларның (язу кәгазьләренең) реквизитлары күрсәтелә, дәүләт теркәвенә алган органның урнашкан урын адресын күрсәтеп))

Салым түләүченең тәңгәллек номеры ___________________________

Лицензия алырга теләүче затны салым органында исәпкә кую турында документ белешмәләре ______________________________________________
_____________________________________________________________.
(лицензиатны салым органында исәпкә кую сәбәбенең коды һәм датасы, лицензиатны салым исәбенә кую турында таныклык реквизитлары (булган очракта))

Лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затының квалификация аттестаты
______________________________________________________________
(квалификация аттестатының номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирелү датасы)

Раслыйм:

- лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яки үтәлмәгән хөкеме юк;

- лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи заты турында лицензиясе юкка чыгарылган лицензиатның бер үзе генә тарафыннан башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашырган затлар, шулай ук лицензиат уставында яки башка документлары нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү бурычы йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган затлар, лицензияләре юкка чыгарылган һәм (яки) үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган шәхси эшкуарлар реестрында мәгълүмат юк;

- лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүче затка элек бирелгән, юкка чыгарылган лицензия турында мәгълүмат юк.

Лицензия алырга теләгән затның телефон (факс) номеры _______________

Лицензия алырга теләүченең электрон почта адресы ___________________

Лицензияләү процедурасы турында хәбәрләмәне электрон формада җибәрүне сорыйм: ______________________________________________________
(әйе / юк)

Мин, _______________________________________________________________,
(лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, ата исеме тулысынча)
«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә үземнең персональ белешмәләремне автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча да, эшкәртүгә, атап әйткәндә «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының беренче өлешендәге 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга, шулай ук минем персональ белешмәләремне Россия Федерациясе Торак кодексының 193 статьясының 1 өлешендәге 3, 4 пунктларында билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүен тикшерү максатларында эшкәртү, тапшыру һәм файдалануга ризалык бирәм.

Уңай карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрыннан өземтә җибәрүегез турында үтенәм[1]

_______________________________________________________________
(электрон документ формасында/кәгазьдә)[2]

Тутыру датасы «__»____________20 __ел.

| _______________________ | _______________________ | _______________________ |
|---|---|---|
| (лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | (лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затының имзасы) | (лицензия алырга теләүче затның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)) |

Мөһер урыны (булган очракта)

_______________________
1 лицензия алырга теләүче зат ихтыярына карап тутырыла
2 лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермәдәге өземтә түләү нигезендә бирелә: Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Лицензияләр реестрыннан кәгазь чыганакта өземтә биргән өчен түләү күләмен, аны алу тәртибен, очракларын һәм кире кайтару тәртибен билгеләү турында» 2020 елның 6 ноябрендәге 742 номерлы боерыгы;

Регламентка 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында
ГАРИЗА

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында сорыйм ____________________
____________________________________________________________________________.
(күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия реквизитлары күрсәтелә)

кем тарафыннан бирелгән ______________________________________________________
____________________________________________________________________________,
(лицензияләүче орган исеме)

_________________________________________________________________ бәйле рәвештә
(күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү нигезе күрсәтелә)

Лицензиатның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган атамасы (шул исәптән фирма исеме) күрсәтелә ____________________________________________________
____________________________________________________________________________.

Лицензиатның оешу-хокук формасы ____________________________________
____________________________________________________________________________.

Лицензиатның урнашкан урыны _________________________________________
____________________________________________________________________________.
(лицензиатның урнашкан урын адресы күрсәтелә)

Юридик затның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) ____________________

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик зат турында белешмәләр кертелү фактын раслаучы документ белешмәләре ________________________________
____________________________________________________________________________.
(дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырган органның урнашкан урын адресын күрсәтеп, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язу кертелүе турында таныклык реквизитлары (юридик затны 2016 елның 31 декабреннән соң теркәгән очракта – язу кәгазенең реквизитлары (язу кертү датасы, дәүләт теркәү номеры) (уставка үзгәрешләр кертелү очрагында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язу кертелүе турында барлык тиешле таныклыкларның (язу кәгазьләренең) реквизитлары күрсәтелә, дәүләт теркәвенә алган органның урнашкан урын адресын күрсәтеп))

Салым түләүченең тәңгәллек номеры ______________________________

Лицензиатны салым органында исәпкә кую турында документ белешмәләре
____________________________________________________________________________.
(лицензиатны салым органында исәпкә кую сәбәбенең коды һәм датасы, лицензиатны салым исәбенә кую турында таныклык реквизитлары (булган очракта))

Лицензиатның вазыйфаи затының квалификация аттестаты ________________
____________________________________________________________________________.
(квалификация аттестатының номеры, кем тарафыннан бирелгән, бирелү датасы)

Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясының $10^1$ өлешендә билгеләнгән мәгълүмат ачуга карата таләпләр нигезендә лицензиат үзенең эшчәнлеге турында мәгълүмат ача торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) рәсми массакүләм мәгълүмат чаралары турында белешмәләр ______________________________________________________________
____________________________________________________________________________.

Лицензиатның телефон (факс) номеры_________________________________

Лицензаитның электрон почта адресы _________________________________

Лицензияләү процедурасы турында хәбәрләмәне электрон формада җибәрүне сорыйм: ____________________________________________________________

(әйе / юк)

Мин, _____________________________________________________________,

(лицензиатның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә үземнең персональ белешмәләремне автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча да, эшкәртүгә, атап әйткәндә «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының беренче өлешендәге 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга, шулай ук минем персональ белешмәләремне Россия Федерациясе Торак кодексының 193 статьясының 1 өлешендәге 3, 4 пунктларында билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүен тикшерү максатларында эшкәртү, тапшыру һәм файдалануга ризалык бирәм.

Уңай карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрыннан өземтә җибәрүегез турында үтенәм[1]

_____________________________________________________________________

(электрон документ формасында/кәгазьдә)[2]

Тутыру датасы «__»____________20 __ел.

| _________________________ | _________________________ | _________________________ |
|---|---|---|
| (лицензиатның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | (лицензиатның вазыйфаи заты имзасы) | (лицензиатның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

Мөһер урыны (булган очракта)

______________________________

1 лицензия алырга теләүче зат ихтыярына карап тутырыла

2 лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермәдәге өземтә түләү нигезендә бирелә: Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Лицензияләр реестрыннан кәгазь чыганакта өземтә биргән өчен түләү күләмен, аны алу тәртибен, очракларын һәм кире кайтару тәртибен билгеләү турында» 2020 елның 6 ноябрендәге 742 номерлы боерыгы;

регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясе
тарафыннан күпфатирлы
йортлар белән идарә итү буенча
эшкуарлык эшчәнлеген
лицензияләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы

Дәүләт торак инспекциясенә

______________________________
(оешма атамасы/
шәхси эшкуарның ФИА)

______________________________
(оешманың адресы/шәхси эшкуарның теркәлү адресы)

E-mail: ______________________
телефон: _____________________

Техник хата төзәтү турында
ГАРИЗА

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм _______
__________________________________________________________________________
(хата төре)

Язылган:__________________________________________________________
__________________________________________________________________.

Дөрес белешмәләр:_________________________________________________
__________________________________________________________________.

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлары белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.________________________________________________________________

2.________________________________________________________________

Уңай карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы лицензияләр реестрыннан өземтәне җибәрергә ____________________________________
(электрон документ формасында/кәгазьдә[1])

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

Тутыру датасы «__»____________20 __ел.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
| (лицензиатның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | (лицензиатның вазыйфаи заты имзасы) | (лицензиатның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

Мөһер урыны (булган очракта)

______________________

[1]лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермәдәге өземтә түләү нигезендә бирелә: Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Лицензияләр реестрыннан кәгазь чыганакта өземтә биргән өчен түләү күләмен, аны алу тәртибен, очракларын һәм кире кайтару тәртибен билгеләү турында» 2020 елның 6 ноябрендәге 742 номерлы боерыгы»;

регламентка 7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә

______________________
(оешма атамасы/
шәхси эшкуарның ФИА)

______________________
(оешманың адресы/шәхси эшкуарның теркәлү адресы)

E-mail: ________________
телефон: ____________________

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия турында мәгълүматлар бирү турында
ГАРИЗА

Татарстан Республикасы күпфатирлы йортлары белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрыннан өземтә бирүегез турында үтенәм әлеге оешма (шәхси эшкуар) буенча ________________________
______________________________________________________________________.
(лицензиянең номеры һәм бирелгән датасы, лицензиатның исеме, ИНН, ОГРН/ОГРНИП күрсәтелә)
Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә җиткерелгән _____________
______________________________________________________________________.
(электрон документ формасында/кәгазьдә1)

Тутыру датасы «__»___________20 __ел.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
| (лицензиатның вазыйфаи затының вазыйфа атамасы) | (лицензиатның вазыйфаи заты имзасы) | (лицензиатның вазыйфаи затының фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

Мөһер урыны (булган очракта)

______________________________

1лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермәдәге өземтә түләү нигезендә бирелә: Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Лицензияләр реестрыннан кәгазь чыганакта өземтә биргән өчен түләү күләмен, аны алу тәртибен, очракларын һәм кире кайтару тәртибен билгеләү турында» 2020 елның 6 ноябрендәге 742 номерлы боерыгы»;

регламентка 9 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә

______________________________
(оешма атамасы/
